| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**29.08.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1716** |

Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы турындагы нигезләмәне раслау хакында

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче, Зеленодольск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән гражданнарны бүләкләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы турындагы нигезләмәне, 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Мактау тактасында урнаштыру өчен кандидатлар раслау буенча комиссия төзергә һәм аның составын 2 нче кушымтада каралганча расларга.
3. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы һәм Мактау китабы турындагы нигезләмәне раслау турында » һәм 2018 елның 04 августындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 21 августындагы «Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы һәм Мактау китабы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2230 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1598 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А.Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 29 августындагы
1716 номерлы карарына
1 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы турында
нигезләмә

## 1.ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Зеленодольск муниципаль районы Мактау тактасы (алга таба - Мактау тактасы) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында яшәүчеләрнең алдынгы эш тәҗрибәсен бүләкләү формаларының берсе буларак тора һәм һөнәри эшчәнлектәге һәм җәмәгать эшендәге югары казанышларга мотивация чарасы.

1.1.Мактау тактасы - ул сәнәгать, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы, азык-төлек сәнәгате, эшмәкәрлек, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт, социаль сәясәт, янгынга каршы хезмәт, хокук саклау органнары һәм муниципаль хезмәт үсешенә зур өлеш керткән гражданнарның фотопортретлары куелган стенд.

Мактау тактасы Мактаулы гражданнар скверында, карап йөрү өчен уңайлы урында, урнаштырыла.

1.2. Фотоны Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасына урнаштыру ел саен Зеленодольск шәһәре көненә багышлап үткәрелә.

1.3. Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатлар Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасына урнаштыру буенча комиссия тарафыннан карала һәм Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.

## 2. МАКТАУ ТАКТАСЫНА КЕРТҮ ТӘРТИБЕ ҺӘМ АНЫ ДОКУМЕНТАЛЬ ЯКТАН РӘСМИЛӘШТЕРҮ

2.1. Мактау тактасына урнаштыру өчен Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 17 августындагы 159 номерлы «Мактау тактасы турында»гы карары белән билгеләнгән өлкәләрдә югары нәтиҗәләргә ирешкән Зеленодольск муниципаль районы халкының кандидатуралары тәкъдим ителә.

2.2. Кандидатураны Мактау тактасына урнаштыру тәкъдиме белән ел саен җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, оешмалар, милек формасына карамастан учреждениеләр, иҗтимагый оешмалар (алга таба - Мөрәҗәгать итүче) мөрәҗәгать итә ала.

2.3. Мөрәҗәгать итүче Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатура турындагы тәкъдимне Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатларны раслау комиссиясенә материаллар кушымтасы белән үтенечнамә, кандидатның Мактау тактасына урнаштыруга язма ризалыгы, кандидатның тәрҗемәи хәле, кандидатның һөнәри, хезмәт, иҗтимагый эшчәнлегенең югары нәтиҗәләре турында сыйфатнамә, кандидатның язма һәм электрон рәвештә фотопортреты җибәрә.

2.3.1. Үтенечнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- Мөрәҗәгать итүченең исеме (кайсы (ведомстводан булуын һәм почта адресын күрсәтеп);

- кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һәм эш урыны;

- Мактау тактасында кандидатны урнаштыру турында нигезләр, тәкъдимнәр;

2.3.2. Кандидатның биографиясендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме (паспорт нигезендә);

- датасы, ае, туган елы;

- эшнең соңгы урыны, вазыйфасы;

- гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме;

- хезмәт һәм йорт адреслары (почта индексларын күрсәтеп) һәм телефон номерлары;

паспорт мәгълүматлары (серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән, яшәү урыны буенча теркәлүе).

2.3.3. Сыйфатнамәдә кандидатның һөнәри, хезмәт һәм иҗтимагый эшчәнлеге, күренекле казанышлары турында төгәл белешмәләр булырга тиеш.

2.4. Материаллар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан имзаланырга тиеш.

2.5. Мактау тактасына урнаштыру турында кабул ителгән карар Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырылырга тиеш.

2.6. Фотопортреты Мактау тактасына куелган гражданнарга тантаналы шартларда Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы имзасы белән Мактау тактасына урнаштыру турында таныклык тапшырыла.

2.7. Мактау тактасында урнаштырылган гражданнар Мөрәҗәгать итүченең карары буенча акчалата премияләр яисә кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнергә мөмкин.

2.8. Әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән материалларны һәм Мактау тактасына урнаштыру турында махсус таныклыкны рәсмиләштерү, исәпкә алу һәм теркәү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

2.8.1. Мактау китабына кертү турындагы таныклык А4 форматындагы кәгазьдә башкарыла.

2.8.2. Таныклыкка түбәндәге мәгълүматлар кертелә:

фамилиясе, исеме, атасының исеме, казанышлары тасвирламасы.

2.8.3. Таныклык бланкларын рәсмиләштерүгә, Мактау тактасына урнаштыру өчен фотопортретлар өчен рамкалар ясауга, шулай ук Мактау тактасын тотуга агымдагы чыгымнарны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

2.9. Мактау тактасына урнаштыру турында таныклык алган гражданнар турында белешмә Мактау тактасында Зеленодольск муниципаль районы халкының фотопортретын урнаштыруны теркәү журналына кертелә.

2.10. Зеленодольск муниципаль районы халкының фотопортретын Мактау тактасына урнаштыруны теркәү журналы «Зеленодольск муниципаль районы музей берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесендә саклана, Мактау китабына язуны Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатларны раслау буенча комиссия секретаре башкара.

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 29 августындагы
1716 номерлы карарына
2 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Мактау тактасына урнаштыру һәм Мактау китабына кертү өчен кандидатларны раслау комиссиясе

## СОСТАВЫ

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфа атамасы |
|---|---|---|
| 1. | Сапожников Д.А. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| 2. | Нуриева Г.Н. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр), рәис урынбасары |
| 3. | Устинова С.А. | «Зеленодольск муниципаль районы музей берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры, секретарь (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары | | |
| 4. | Антипов К.С. | «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» ФДУП профсоюз комитеты рәисе, Зеленодольск шәһәре Мэры урынбасары (килешү буенча) |
| 5. | Хәбибуллин З. Ф. | Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының җирлекләр белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча) |
| 6. | Яковлева М.Н. | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының оештыру бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 7. | Анисимов Д.С. | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 8. | Перова Е.А. | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 9. | Старостин А. В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 10. | Афанасьева Р. В. | Җитәкче урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы |
| 11. | Лулаков Д.В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы |
| 12. | Гыйззәтуллин Т.Р. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы ветераннарының (пенсионерларының) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе |
| 13. | Фролова Н.Ф. | Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча) |